**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**«Югары Кәминкә авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлегенең**
**гражданнары җыены**
**карары**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Югары Кәминкә авыл җирлеге составына керүче Ибрай Каргалы торак пунктында

**24 октябрь 2023 ел** **№ 4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегенең Ибрай Каргалы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2024 елда Югары Кәминкә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә гражданнарның үзара салымын кертергә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш.

2. Алынган чараларны җибәрергә:

- Югары Кәминкә, Ибрай Каргалы, Кызыл Яр торак пунктларында урам яктырту челтәрләрен ремонтлау, урам утларын кую, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга;
- Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау. Югары Кәминкә авылы, Ибрай Каргалы авылы, Кызыл Яр авылы торак пунктларында су белән тәэмин итү чыганаклары территориясенең санитар саклау зонасын төзекләндерү, эчә торган су анализларын үткәргән өчен түләү;
- Югары Кәминкә авылы, Ибрай Каргалы авылы, Кызыл Яр авылы торак пунктларында яр буе зоналарын, елга үзәненең сулыкларын чистарту, туфракны (ләмне) чыгару, биек агачларны кисү;
- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту, җәйге һәм кышкы вакытта хезмәт күрсәтү, җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен ремонтлау, ягулык-майлау материаллары, запас өлешләр, кирәкле материаллар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү;

- Коймаларны ремонтлау, төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, дератизация чараларына түләү;
- Халыкның күпләп ял итү урыннарын (балалар мәйданчыкларын, спорт мәйданчыкларын, паркларны, яр буйларын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү, адреслы такталар ясау;
- Башкарылган эшләрнең барлык төрләре буенча проект-смета документациясе өчен түләү

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Югары Кәминкә авыл җирлеге башлыгы М.Н.Минһаҗев